

Мордовиядә «Ин яхшы мәктәп ашханәсе – 2024» Ботенроссия конкурсы узды.
Әлеге ярыш дvртенче тапкыр Россия Мәгариф министрлыгы эгидасы астында уздырыла һәм ана кызыксыну даими рәвештә арта. Конкурс vз эшенен профессионалларын берләштерә, алар ана жаннарын һәм мәхәббәтләрен сала.
Регионыбызга илнен 75 тобәгеннән командалар һәм мәктәп пешекчеләре килде. Республика мәдәният сараенда һәр субъект мәктәп туклануына керә торган тәмле ризыклар белән тосле стенд оештырды. Мордовия Главасы Артём Здунов стендларны карады, делегация вәкилләре белән аралашты. Һәр команда ризыкларны бизәvгә һәм эчтәлегенә ижади һәм зур жаваплылык белән килгәннәр. Барлык тобәкләр дә vзләренен колоритларын чагылдырдылар һәм кулинариядә югары осталыкларын кvрсәттеләр. Кайбер стендларда милли уен коралларында жырлар һәм музыка янгырады.
Катнашучыларны сәламләп, ин-де дvрт ел дәвамында РФ Дәvләт Советынын мәктәп туклануы мәсьәләләре комиссиясенен эш торкемен житәкләгән Артём Здунов ассызыклаганча: балаларны балансклы, сыйфатлы дорес тукландыру - киләчәк буыннарнын сәламәтлеге нигезе. «Әгәр без балаларга сәламәт туклану кvнекмәләрен ойрәтсәк, алар киләсе буыннарга тапшырылачак. Бу идеологик бурыч: сәламәт туклану – илебезнен озак елларга иминлеге ул!» - диде республика житәкчесе. Россия Президенты кушуы буенча барлык башлангыч мәктәп укучылары да тvләvсез кайнар ризык белән тәэмин ителә. Хәзер СВОда катнашучы гаиләләрдәге һәм кvп балалы гаиләләрдәге балаларга аерым игътибар бирелә. Балалар учреждениеләренә эләгә торган продуктларнын сыйфатына катгый контроль алып барыла. Мордовиядә мона бик зур игътибар бирелә.
Артём Алексеевич билгеләп vткәнчә, конкурста республика кочле кондәшлек кvрсәтә. Мәктәптә туклану белән тәэмин итvчеләр арасында 80% тан артыгы - жи



рле товар житештерvчеләр. Бу тема республика балаларынын vзләрен дә бик кызыксындыра - кvпләр «Момкинлекләр доньясы» партия проектында катнаша, бигрәк тә «Сәламәт туклану» акциясе популяр.
- Конкурс сынаулары бара инде. Без тобәкләрдә мәдәни традицияләрнен никадәр бай һәм кvпторле булуына инандык. Конкурс нәтижәләре мәктәп туклануы очен момкин кадәр алга китәргә һәм рациональ меню формалаштырырга момкинлек бирәчәк. Бу чаралар без vз сокыбызда пешмәсен, ә бер-беребездән ойрәнсен һәм коралга ин яхшысын алсын очен кирәк. Моны безнен ил кешеләре буыннар аша сәламәт булсын очен эшлибез! - дип нәтижә ясады Мордовия Главасы.
Шулай ук барлык тәкъдимнәр, моһим инициативалар һәм алга киткән эшләнмәләр һичшиксез РФ Дәvләт Советы комиссиясе материалларына керәчәк, ә Роспотребнадзор белән берлектә даими рәвештә балалар сәламәтлеге торышы срезлары vтәчәк, дип билгеләп vтелде.
Барлык конкурс сынаулары йомгаклары буенча дvрт номинациядә жинv-челәр һәм

призерлар бил-геләнәчәк: мәктәп ашханәсенен ин яхшы пешекчесе, шәһәр мәктәбенен ин яхшы ашханәсе, авыл мәктәбенен ин яхшы ашха-нәсе, миллионлы шәһәрнен ин яхшы мәктәп ашханәсе. Шулай ук быел конкурста яна номинация – «Мәктәп туклануына җәмәгать (ата-ана) бәясе рейтингы» тәкъдим ителде.
Мәктәп ашханәләренен ин яхшы пешекчеләре беренче конне vк билгеләнде. Призерларны һәм жинvче-ләрне Мордовия Главасы Артём Здунов һәм РФ Мәгариф министрлыгынын укучыларнын туклануын мониторинглау федераль vзәге директоры Валентина Иванова бvләкләде. Ярышларда Тамбов олкәсеннән Алевтина Шаповалова һәм Мордовиядән Анна Докучаева лидер булдылар.
Мәктәптә туклануны vстерvгә һәм камилләштерvгә керткән олеше очен Мордовия Республикасы Главасынын Рәхмәт хаты Валентина Ивановага тапшырылды. Ул чыгышында:

- Илнен мәктәп туклануы vсешенә Мордовия зур олеш кертте. Монын очен сезгә бик зур рәхмәт, Артём Алексеевич. Безгә республикадан ойрәнер нәрсәләр бар! - диде федераль vзәк директоры. - Алда ике кон житди сынаулар һәм Ботенроссия фәнни-гамәли конференциясе, анда барлык тобәкләрнен ин яхшы тәжрибәсе ойрәнеләчәк. Без балалар сәламәтлеге, милләтебез, мәгариф системасынын һәм илебезнен киләчәге очен эшлибез.
Кvргәзмәдә милли татар ашларыбызны Татарстан һәм Башкортстан мәктәпләрендә рәхәтләнеп кулланалар. Башкортстан республикасы Нефтекамск шәһәре 17 мәктәп директоры Роман Тагир улы Ганиев (конкурста катнашучылар: әйдәп баручы белгеч Лириса Борисовна Галиева, тук-лануны оештыручы Зинифә Фларид кызы Умурбаева, җәмәгать туклануы технологы Ирина Александровна Хәйруллина) белән әнгәмәдән кvргәзмәгә куелган очпочмак, боккән, вак бәлеш, чәк-чәк һәм башка милли ашлар рецептында файдасыз жирларны кулланмый пешерvләре турында сойләде. Ул фенилкетонурия белән авырган балалар очен яраклаштырылган аш-су белән ашатуларына аерым басым ясады.
Ниһаять нәтижәләр ясалды. Быел чарага илнен 75 тобәгеннән 110 команда һәм 50 мәктәп пешекчесе килгән иде. Лауреатлар арасында - «Авыл мәктәбенен ин яхшы ашханәсе» номинациясендә 2 нче Ромоданово урта мәктәбе, «Мәктәп туклануына җәмәгать (ата-аналар) бәясе рейтингы» нда 3 тобәк командасы лидер булды: Мордовия Республикасы, Хабаровск крае, Хакасия Республикасы. Әлеге командалар да 12 ноябрьдә Мәскәvдә vткән суперфиналда катнашты.

**Наилә НАСЫРОВА**